ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАЛТАСИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЛТАЧ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» декабрь 2020 ел № 65

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга шартнамә төзү хокукына аукцион уздыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 20 июнендәге 12/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Акционер җәмгыятьләр турында» 1995 елның 26 декабрендәге 208-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр турында» 1998 елның 8 февралендәге N 14-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетынын 13.08.2016 елгы 553 нче номерлы «дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки муниципаль милектәге җир кишәрлекләрендә, шулай ук җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп Балтач шәһәр җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 20 июнендәге 12/1 номерлы карары белән расланган «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга шартнамә төзү хокукына аукцион үткәрү тәртибе турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 15 пунктның «в» пунктында «мөрәҗәгать итүченең таныкланган мөһере» сүзләреннән соң «(мөһер булу турындагы белешмәләр җәмгыять уставында булса)» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының

рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Балтач шәһәр җирлеге башкарма комитеты сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Балтач шәһәр җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе И.Д.Габдрахманов